**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXIII СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 132**

Мөслим авылы «14» декабрь 2022 ел

**«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисе, Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләме турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2021 елның 14 декабрендәге 71 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны, Федераль дәүләт граждан хезмәткәрләрен, федераль дәүләт органнары хезмәткәрләрен, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә федераль дәүләт граждан хезмәте булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләрне командировкага җибәрү үзенчәлекләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 17 октябрендәге 752 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисе, Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләме турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2021 елның 14 декабрендәге 71 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.3.1 пункты белән тулыландырырга:

«3.3.1. Хезмәткәр Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә хезмәт командировкаларында булган чорда:

а) акчалата бүләкләү (акчалата түләү) икеләтә күләмдә түләнә;

б) даими яшәү урыныннан читтә яшәү белән бәйле өстәмә чыгымнар (тәүлеклек) хезмәт командировкасында булган һәр көн өчен 8480 сум күләмендә каплана».

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында http://muslumovo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мөслим муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р. Г. Гариповка йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р.Хуҗин